**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЧҮРИ-БУРАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

12 октябрь 2018 ел №15

**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Чүри-Бураш авыл җирлеге Башкарма комитетының “Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы “Чүри-Бураш авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру турында " 2017 ел, 9 март, 4 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының "Чүри-Бураш авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына нигезләнеп Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Чүри-Бураш авыл җирлеге башкарма комитеты **карар итә:**

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Чүри-Бураш авыл җирлеге башкарма комитетының "Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Чүри-Бураш авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру турында” 2017 ел, 9 март, 4 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы "Чүри-Бураш авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыруга шартнамә төзү хокукына аукцион үткәрү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 16 пунктның «в» пунктчасында «мөрәҗәгать итүченең мөһере белән расланган " сүзләреннән соң «(әгәр җәмгыять уставында мөһер булу турындагы мәгълүматлар бар икән)»сүзләрен өстәргә.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Чүри-Бураш авыл җирлеге Уставы белән билгеләнгән тәртип нигезендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм махсус мәгълүмати стендларда бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдәкалдырам.

**Чүри-Бураш авыл**
**җирлеге башлыгы** **И.Р.Мифтахов**